РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 гыйнвар 2025 ел Буа шәһәре № 2-72

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Буа район Советының 2013 елның 20 декабрендәге 4-37 номерлы карары (28.05.2015 № 1-49, 15.07.2016 № 9-1, 15.09.2017 № 6-24, 09.11.2018 № 2-35, 26.07.2019 № 4-42, 26.02.2020 № 6-50, 09.07.2021 № 1-14, 21.10.2022 № 1-35, 15.12.2023 № 4-56 ТР Буа районы Советы карарлары редакциясендә) белән кабул ителгән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 86-88 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

**I.** «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы Карары проектын (1 нче кушымта) беренче укылышта кабул итәргә.

**II.** Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау өчен түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

-эшче төркем җитәкчесе:

Еремеев Илдар Фәрит улы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары,

- эш төркеме әгъзалары:

Шакирҗанов Ленар Рафик улы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Сибгатуллин Әнсар Мансур улы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе;

Вәлиева Резеда Нәгыйм кызы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының җирлекләр җирле үзидарәсе органнары белән эшләү бүлеге башлыгы;

Сафиуллина Лилия Рәшит кызы – Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы.

**III.** Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектына тәкъдимнәр ТР Буа районы Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422430, ТР, Буа районы, Буа ш., Жорес ур., 110а й., язма рәвештә, карар проекты рәсми басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларда катнашып чыгыш ясау хокукы өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 422430, ТР, Буа районы, Буа ш., Жорес ур., 110а й, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарның әлеге проекты буенча Буа район Советының 2007 елның 14 маендагы 5-16 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында гавами тыңлаулар үткәрү турында нигезләмәдә» каралган тәртиптә, аларны 2025 елның 12 февраленә билгеләп, 10.00 сәгатьтә Буа Башкарма комитетының утырышлар залында күрсәтелгән адресы буенча: 422430, ТР, Буа районы, Буа ш., Жорес ур., 110 А. гавами тыңлаулар үткәрергә.

**IV.** Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга (https://buinsk.tatarstan.ru).

**V.** Кушымтаның 1.1 пунктының беренче абзацында, 1.2 нче пунктта, 1.9 нчы пунктның икенче һәм бишенче абзацларында каралган үзгәрешләр 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

**VI.** Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проектына тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

**VII.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Буа районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (рәисе А.М. Сибгатуллин).

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов

ТР Буа муниципаль районы Советының
2025 елның 23 гыйнварындагы
2-72 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Буа район Советының 2013 елның 20 декабрендәге 4-37 номерлы карары (28.05.2015 № 1-49, 15.07.2016 № 9-1, 15.09.2017 № 6-24, 09.11.2018 № 2-35, 26.07.2019 № 4-42, 26.02.2020 № 6-50, 09.07.2021 № 1-14, 21.10.2022 № 1-35, 15.12.2023 № 4-56 ТР Буа районы Советы карарлары редакциясендә) белән кабул ителгән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 86-88 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

**I.** Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 статья :

1 өлешнең 27 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

33 пунктта «, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләреннән» сүзләрен өстәргә;

1.2. 7.1 статья :

17 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

1.3. 8 статья:

икенче абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекләргә бу максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы булалар.».

1.4. 26 статья:

6 өлешнең 2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

9 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. 29 статья:

1 өлешнең 26 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат

чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

1.6. 29 статья :

1 өлешнең 15 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.7. 35 статья :

1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 11.1 пункт өстәргә:

«10.1 аның чит ил агенты статусын алуы;»;

1.8. 38 статья :

5 өлешнең 2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.9. 41статья :

7 өлешнең 2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.10. 44 статья :

3 пунктның бишенче абзацын 1 өлештә үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

1 өлештәге 6 пунктның алтынчы абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

8 пунктның бишенче абзацында 1 өлештә «, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләреннән» сүзләрен өстәргә.;

10 пунктның унөченче абзацында 1 өлештә «федераль законнарда» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законда, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алмаштырырга.;

10 пунктның унҗиденче абзацын 1 өлештә үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

1.11. VIII бүлекне һәм 55 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

1.12. 65 статья:

җиденче абзацта «муниципаль берәмлекнең даими нигездә эшләүче һәм комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче юридик зат булып торучы сайлау комиссиясе әгъзасы» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.13. 73 статья :

3 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек була торган оешмаларның хокукый статусын билгели

торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.».

1.14. 76 статья :

1 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда Муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар.».

**II.** Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2013 елның 20 декабрендәге 4-37 номерлы карары (28.05.2015 № 1-49, 15.07.2016 № 9-1, 15.09.2017 № 6-24, 09.11.2018 № 2-35, 26.07.2019 № 4-42, 26.02.2020 № 6-50, 09.07.2021 № 1-14, 21.10.2022 № 1-35, 15.12.2023 № 4-56 ТР Буа районы Советы карарлары редакциясендә) белән кабул ителгән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының үзгәртелгән нигезләмәләренең яңа редакциясен хупларга

**III.** Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башлыгына әлеге карарны «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

**IV.** Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (http://pravo.tatarstan.ru/) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**V.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов